**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 28 августындагы 2985 номерлы карары**

**Бәйсез Дәүләтләр Берлегендә катнашучы дәүләтләрнең пенитенциар хезмәтләр җитәкчеләре Советының XI утырышын, Бәйсез Дәүләтләр Берлегендә катнашучы дәүләтләрнең генераль прокурорлары Координация советының 36 нчы утырышын һәм Шанхай хезмәттәшлек оешмасында катнашучы дәүләтләрдәге генераль прокурорларның 24 нче утырышын, Россия Федерациясе субъектларының гражданлык хәле актларын теркәү органнары җитәкчеләре белән Бөтенроссия киңәшмәсен, Ислам дәүләтләренең стандартлаштыру һәм метрология институты (SMIIC) Генераль ассамблеясының 21 нче утырышын әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә Бәйсез Дәүләтләр Берлегендә катнашучы дәүләтләрнең пенитенциар хезмәтләр җитәкчеләре Советының XI утырышын, Бәйсез Дәүләтләр Берлегендә катнашучы дәүләтләрнең генераль прокурорлары Координация советының 36 нчы утырышын һәм Шанхай хезмәттәшлек оешмасында катнашучы дәүләтләрдәге генераль прокурорларның 24 нче утырышын, Россия Федерациясе субъектларының гражданлык хәле актларын теркәү органнары җитәкчеләре белән Бөтенроссия киңәшмәсен, Ислам дәүләтләренең стандартлаштыру һәм метрология институты (SMIIC) Генераль ассамблеясының 21 нче утырышын әзерләү һәм уздыру чорында юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү максатыннан:

1. **Карар бирәм**:

1.1. чараларны әзерләү һәм уздыру чорында әлеге карарның 1, 2, 3, 4 номерлы кушымталары нигезендә Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне билгеләргә;

1.2. юл хәрәкәтен оештыруда техник чараларны һәм таранга каршы техниканы урнаштыру өчен «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерцияле булмаган оешма (алга таба – Оештыручы) җаваплы дип билгеләргә;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.3.1. хәрәкәтне вакытлыча чикләү чорында юл билгеләрен урнаштыруда һәм каплауда Оештыручыга ярдәм күрсәтергә;

1.3.2. транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм МТС.URENT) һәм велосипедлар («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарда күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю эшен оештырырга;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе (А.И.Салихов) белән берлектә хәрәкәтне вакытлыча чикләү чорында таранга каршы техника урнаштыруда Оештыручыга ярдәм күрсәтергә;

1.5. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карарның кушымталары нигезендә Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларында җәмәгать тәртибен саклауны оештырырга, юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) массакүләм мәгълүмат чаралары аша Казан шәһәренең

автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләү кертелүе турында хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 28 августындагы
2985 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Бәйсез Дәүләтләр Берлегендә катнашучы дәүләтләрнең пенитенциар хезмәтләр җитәкчеләре Советының XI утырышын әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү графигы**

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2026 елның<br>10 сентябрендә 20.00 сәгатьтән 2026 елның<br>11 сентябрендә 23.59 сәгатькә кадәр<br>(кирәк булганда) | Пушкин урамында, Карл Маркс урамыннан Большая Красная урамына кадәрге участокта (ике юнәлештә);<br>Театр урамында, Карл Маркс урамыннан Большая Красная урамына кадәрге участокта (ике юнәлештә);<br>К.Маркс урамында (муниципаль тукталыш территориясе), Пушкин урамыннан Театр урамына кадәрге участокта |

____________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 28 августындагы
2985 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Бәйсез Дәүләтләр Берлегендә катнашучы дәүләтләрнең генераль прокурорлары Координация советының 36 нчы утырышын һәм Шанхай хезмәттәшлек оешмасында катнашучы дәүләтләрдәге генераль прокурорларының 24 нче утырышын әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү графигы**

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2026 елның 13 сентябрендә 22.00 сәгатьтән 2026 елның 18 сентябрендә 23.59 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | «Ак Барс Арена» стадионы тирәсендәге әйләнеп узу юлында |
| 2 | 2026 елның 29 сентябрендә 20.00 сәгатьтән 2026 елның 1 октябрендә 23.59 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | Пушкин урамында, Карл Маркс урамыннан Большая Красная урамына кадәрге участокта (ике юнәлештә); Театр урамында, Карл Маркс урамыннан Большая Красная урамына кадәрге участокта (ике юнәлештә); К.Маркс урамында (муниципаль тукталыш территориясе), Пушкин урамыннан Театр урамына кадәрге участокта |

___________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 28 августындагы
2985 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

**Россия Федерациясе субъектларының гражданлык хәле актларын теркәү органнары җитәкчеләре белән Бөтенроссия киңәшмәсен әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү графигы**

| №<br>т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2026 елның<br>4 октябрендә 20.00 сәгатьтән 2026 елның 10 октябрендә 23.59 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | Һ.Такташ урамы, М.Сәлимҗанов урамындагы кереп туктау уемнарын да кертеп, Спартак урамыннан М.Сәлимҗанов урамына кадәрге участокта (ике юнәлештә) |

______________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 28 августындагы
2985 номерлы карарына
4 номерлы кушымта

**Ислам дәүләтләренең стандартлаштыру һәм метрология институты (SMIIC) Генераль ассамблеясының 21 нче утырышын әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү графигы**

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2026 елның 27 октябрендә 20.00 сәгатьтән 2026 елның 28 октябрендә 23.59 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | Пушкин урамында, Карл Маркс урамыннан Большая Красная урамына кадәрге участокта (ике юнәлештә); Театр урамында, Карл Маркс урамыннан Большая Красная урамына кадәрге участокта (ике юнәлештә); К.Маркс урамында (муниципаль тукталыш территориясе), Пушкин урамыннан Театр урамына кадәрге участокта |

____________________